**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6049**
**16.11.2020**

Башкарма комитетның «Законсыз эшмәкәрлеккә каршы тору буенча ведомствоара комиссия турында» 2015 елның 10 мартындагы 1431 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Законсыз эшмәкәрлеккә каршы тору буенча ведомствоара комиссия турында» 2015 елның 10 мартындагы 1431 номерлы карарына (2016 елның 15 июнендәге 2967 номерлы, 2017 елның 24 мартындагы 1561 номерлы, 2019 елның 10 сентябрендәге 4591 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада:

законсыз эшмәкәрлеккә каршы тору буенча ведомствоара комиссия составыннан Е.В. Григорьеваны чыгарырга;

законсыз эшмәкәрлеккә каршы тору буенча ведомствоара комиссия составына Башкарма комитетның Комсомол районы хакимиятенең территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлеге башлыгы А.С. Нуруллинаны кертергә;

2) 2 нче кушымтада:

законсыз эшмәкәрлеккә каршы тору буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 10-12 пунктчаларны өстәргә:

«10) законсыз эшмәкәрлекне профилактикалау һәм аңа каршы торуга юнәлдерелгән чаралар оештыру;

11) башкарма хакимият органнары, хокук саклау органнары белән үзара, шул исәптән мәгълүмати эшчәнлекне тәэмин итү;

12) законсыз эшмәкәрлекне ачыклау, шулай ук алга таба тиешле чаралар күрү максатыннан хокук куллану практикасы мониторингын гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А Кропотовага, Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыкларына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов